# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Олы Кайбыч торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**19 ноябрь, 2021 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның «11» ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, 2021 елның «12» ноябрендә 08 сәгать 00 минутта, 2021 елның «12» ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, 2021 елның «15» ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2021 елның «15» ноябрендә 14 сәгать 30 минутта, 2021 елның «16» ноябрендә 14 сәгать 00 минутта, 2021 елның «17» ноябрендә 15 сәгать 00 минутта, 2021 елның «18» ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2021 елның «19» ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Олы Кайбыч авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сумм күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?» соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- материаллар сатып алып, паркларны төзекләндерү;
- территорияләрне санкцияләнмәгән чүплекләрдән чистарту;
- материаллар сатып алып, чишмәләрне ремонтлау һәм территорияләрен төзекләндерү;
- материаллар сатып алып, тротуарлар ясау;
- материаллар сатып алып, балалар мәйданчыкларын төзекләндерү;
- материаллар сатып алып, җәяүлеләр күперләрен ремонтлау;
- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- материаллар сатып алып, зиратларны чистарту һәм ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1217 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 633, бу 52 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 633 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Олы Кайбыч торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен –дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Олы Кайбыч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- материаллар сатып алып, паркларны төзекләндерү;
- территорияләрне санкцияләнмәгән чүплекләрдән чистарту;
- материаллар сатып алып, чишмәләрне ремонтлау һәм территорияләрен төзекләндерү;
- материаллар сатып алып, тротуарлар ясау;
- материаллар сатып алып, балалар мәйданчыкларын төзекләндерү;
- материаллар сатып алып, җәяүлеләр күперләрен ремонтлау;
- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- материаллар сатып алып, зиратларны чистарту һәм ремонтлау.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Кайбыч авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Сунгатуллин